Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 23**

Олы Солтан ав. 14 нче декабрь 2016 ел

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлешеТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Солтан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советы карар бирә:

1 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

-авыл җирлекләренең генераль планнарын, авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны раслау, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 июлендә кабул ителгән 13 номерлы «Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы,

Р.Шәрәфиев урамы, 12 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

СОВЕТ
БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000725
ОЛЫ СОЛТАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ